Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №Х-4**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 28 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, "Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль законга, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы тору турында" Законга, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законына һәм "Муниципаль хезмәт турында" Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында" 2020 елның 26 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 22.07.2013 елгы XXVII-6, 14.08.2014 ел XXXIX-3, 13.12.2014 ел XLII-8, 14.11.2015 ел V-3, 23.04.2016 ел X-8, 16.11.2016 ел XIII-9, 29.05.2017 ел XIX-9, 23.10.2017 ел XXII-6, 24.07.2018 ел XXXII-4, 19.11.2018 ел XXXVI-5, 20.12.2018 ел XXXVII-2, 01.04.2019 ел XLI-11, 22.07.2019 ел XLIV-4, 24.09.2019 ел XLV-13, 17.02.2020 ел L-4, 05.08.2020 ел LIV-9, 06.10.2020 елгы II-1номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 маддәнең 4.15 пунктында "хезмәт кенәгәсен" сүзләреннән соң "(булган очракта)" сүзләрен өстәргә;

2) 6 маддәнең 6.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәр урынбасары булган муниципаль хезмәткәр мәнфәгатьләр низагын булдырмау максатларында әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында аларның тиешле вазыйфасын биләү чорында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмыйлар."

3) 9 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 9.12 пунктны өстәргә:

“9.12. Әлеге Нигезләмәнең максатлары өчен "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә цифрлы валюта мөлкәт дип танылa.”

4) 10.1.3 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт кенәгәсен һәм (яки) мәгълүматларны, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан гайре;”;

5) 16.9 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яки) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, шулай ук, кирәк булганда, муниципаль хезмәт стажын раслый торган һәм әлеге Нигезләмәнең 17 маддәсендә күрсәтелгән башка документларның күчермәләре;”;

6) 17 маддәнең 17.6.3 пунктында:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Муниципаль хезмәт стажын раслаучы төп документлар – билгеләнгән үрнәктәге хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән мәгълүматлар.”;

б) дүртенче абзацта “хезмәт кенәгәсе” сүзләреннән соң “һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар “ сүзләрен өстәргә;

7) 20 маддәнең 20.1 пунктындагы 4 пунктчасына түбәндәге сүзләрне өстәргә: “(булган суРәттә), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат формалаштыру һәм күрсәтелгән мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмати ресурсларында саклау өчен бирү”;

8) 20 маддәнең 20.6.11 пунктындагы 4 пунктчасында “хезмәт кенәгәсе күчермәсен” сүзләрен “законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яки) хезмәт кенәгәсенең күчермәсен” сүзләренә алмаштырырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Ф.Г. Әхмәтҗанова